СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-36 от «14» ноября 2019 г.

Мамадыш муниципаль районында авыл хуҗалыгы җитештерүенең кече формаларына ярдәм итү буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыруның барышы турында

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең динамик икътисадый үсешен, авыл халкын эш белән тәэмин итүдә кече хуҗалык формаларының ролен арттыру һәм аның тормыш дәрәҗәсен яхшырту максатларында, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В. И. Никитинның Мамадыш муниципаль районында авыл хуҗалыгы җитештерүенең кече формаларына ярдәм итү буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И. Никитинның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә, авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру максатларында, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәрьяклы ярдәм күрсәтергә, авыл хуҗалыгы кооперативларының тотрыклы эшен оештыру өчен шартлар тудырырга тәкъдим итәргә.

- Мамадыш муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүче субъектларда «Агросәнәгать комплексын үстерү» өстенлекле милли проектының максатчан күрсәткечләрен үтәү буенча алга таба эшне активрак алып барырга;

- эш урыннары булдыру һәм грант алучыларның гаилә фермаларын, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларның мини-фермаларын йөкләү буенча максатчан эш алып бару;

- агросәнәгать комплексына ярдәм итү буенча республика программаларында актив катнашу буенча гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына консультатив ярдәм күрсәтергә.

3. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына милли проектларны тормышка ашыру һәм «Авыл

территорияләрен комплекслы үстерү» (2020 — 2025 еллар) яңа дәүләт программасын үтәү аша авылның социаль — мәдәни инфраструктурасын яхшырту буенча актив эш алып барырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://mamadysh.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов